КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 сентябрь г.Казань № 781

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аланың мрөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләт-ләрен регламентлаштыру өлешендә «Дәү-ләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аларның мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентлаштыру өлешендә «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 май,

388 нче; 2012 ел, 20 октябрь, 879 нчы; 2018 ел, 21 апрель, 275 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аларның мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта:

өченче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре) гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла.»;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктта «Р.Ф.Моратов» сүзләрен «Р.К.Нигъмәтуллин» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибендә:

преамбулада «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 31 статьясындагы 15 өлеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә кую юлы белән Татарстан Республикасы учреждениесен төзү (алга таба – Татарстан Республикасы учреждениесен төзү) төзеләчәк учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарачак республика башкарма хакимият органы инициативасы белән яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган) инициативасы белән гамәлгә ашырыла.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы учреждениесен төзү турында карар проекты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад

министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган), «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелергә тиеш.»;

12 пунктта «гамәлгә кую юлы белән учреждение төзү тәртибе кебек» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 4 – 10 пунктларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның «б» пунктчасында «халык өчен мондый оешма һәм аның тарафыннан башкарыла торган сыйфат» сүзләрен «халык өчен Татарстан Республикасы учреждениеләре һәм башкарыла торган сыйфат» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы учреждениесен үзгәртеп оештыру турында карар проекты үзгәртеп оештырыла торган учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган тарафыннан әзерләнә һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелергә тиеш.»;

21 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Республикасы учреждениеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

22 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Респуликасы учреждениеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

23 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Респуликасы учреждениеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

24 пунктның беренче абзацына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

25 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасына аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын җибәрә. Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелергә тиеш.»;

27 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

28 пунктның «в» һәм «г» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әгәр Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы автоном учреждениесе төзелсә, Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турында аңлатма язуын һәм тәкъдимне теркәп, Татарстан Республикасы төрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы бюджет яисә казна учреждениесенә килештерүгә җибәрә.

Әгәр Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы казна яки бюджет учреждениесе барлыкка килгән булса, җибәрелгән вакыттан алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы учреждениесе җитәкчесенә Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турында карар проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрү турында хәбәр итә;

г) әлеге пунктның «в» пунктчасындагы беренче абзацында каралган очракта, килештерелгән вакыттан алып өч эш көне эчендә аңлатма язуын, Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турындагы тәкъдимне теркәп һәм бюджет яки казна учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә. Татарстан Республикасы учреждениесе төрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелергә тиеш.»;

32 пунктта:

дүртенче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

37 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына» сүзләрен «мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органга» сүзләренә алмаштырырга;

39 пунктның «г» пунктчасында:

дүртенче абзацта татар текстында «учреждениеләре» сүзе алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «милекче» сүзен «Татарстан Республикасы учреждениесенең мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «дәүләт реестрында исәпкә алу өчен мөлкәт» сүзләрен «реестрына кертү өчен мөлкәт турында мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «аңа милекче тарафыннан» сүзләрен «аңа Татарстан Республикасы учреждениесенең мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга, «аңа милекче тарафыннан» сүзләрен «аңа Татарстан Республикасы учреждениесенең мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «мөлкәт милекчесе карары буенча һәм аның» сүзләрен «һәм» сүзенә алмаштырырга;

43 һәм 44 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43. Татарстан Республикасы учреждениесе уставы проекты кергән датадан 15 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республи-

касы учреждениесенең мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелергә тиеш. Нигезле искәрмәләр булган очракта, Татарстан Республикасы учреждениесе уставы проекты әлеге срок эчендә эшләп бетерү өчен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органга кире кайтарыла.

44. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган әлеге Тәртипнең 43 пунктында күрсәтелгән органнар белән килештерелгән Татарстан Республикасы учреждениесе уставы проекты кергән датадан алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы учреждениесе уставын раслау турында хокукый акт чыгара яисә күрсәтелгән срок эчендә эшләп бетерү өчен Татарстан Республикасы учреждениесенә кире кайтара.

Татарстан Республикасы учреждениесенең расланган уставы кәгазь чыганакта кимендә өч нөсхәдә дәүләт теркәвенә җибәрелә.»;

46 – 49 пунктларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«46. Татарстан Республикасы учреждениесенең яңа редакциядәге уставын раслау, Татарстан Республикасы учреждениесе уставының гамәлдәге редакциясенә үзгәрешләр кертү өчен Татарстан Республикасы учреждениесе тарафыннан гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органга түбәндәгеләр җибәрелә:

Татарстан Республикасы учреждениесе уставының яңа редакциясе;

Татарстан Республикасы учреждениесе уставына кертелә торган үзгәрешләр;

Татарстан Республикасы учреждениесенең гамәлдәге уставының барлык кертелә торган үзгәрешләре белән күчермәсе.

47. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган кергән вакыттан алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы учреждениесе уставының яңа редакциясе, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына кертелә торган үзгәрешләрнең федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры килүенә тикшерүне, Татарстан Республикасы учреждениесенең мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органга, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә килештерүгә җибәрүне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы учреждениесе уставының яңа редакциясе, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына үзгәрешләр кергән датадан 10 көн эчендә килештерелергә яисә, искәрмәләр булганда, эшләп бетерү өчен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органга кире кайтарылырга тиеш.

48. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган әлеге Тәртипнең 47 пунктында күрсәтелгән органнар белән килештерелгән Татарстан Республикасы учреждениесенең яңа редакциясе уставы, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына үзгәрешләр кергән датадан 10 көн эчендә Татарстан Республикасы учреждениесенең яңа редакциясе уставын раслау, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына үзгәрешләр кертү турында хокукый акт чыгара, килештерү барышында алынган искәрмәләр булганда, эшләп бетерү өчен Татарстан Республикасы учреждениесенә кире кайтара.

Татарстан Республикасы учреждениесенең расланган уставы, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына кертелә торган үзгәрешләр кәгазь чыганакта кимендә өч нөсхәдә дәүләт теркәвенә җибәрелә.

49. Татарстан Республикасы учреждениесе уставы, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына кертелә торган үзгәрешләр дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы учреждениесе, дәүләт теркәвенә алынган датадан алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт теркәвенә алу турында белге белән Татарстан Республикасы учреждениесе уставын, Татарстан Республикасы учреждениесе уставына кертелә торган үзгәрешләрне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы органга кертә.»;

әлеге Тәртипнең кушымтасында:

1.1 пунктта татар текстында «учреждениеләре» сүзе алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

2.5 пунктта «Ф.И.Ат.ис.» сүзләрен «Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта «милекче турында» сүзләрен «милекче функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган турында» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктта «учреждениенең күчемле мөлкәте» сүзләрен «күчемле мөлкәт» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы җитәкчесе Ф.И.Ат.ис. һәм имзасы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы мөһере» сүзләрен «М.У.» сүзләренә алмаштырырга;

«*» искәрмәсендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

«**» искәрмәсендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле дәүләт органы» сүзләрен «мөлкәт милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәдә:

исемендә «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр Татарстан Республикасы законнары белән башкасы билгеләнмәсә, бюджет учреждениесенә карата гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән тармак компетенциясендәге республика башкарма хакимият органы яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан (алга таба – гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган) гамәлгә ашырыла.»;

3 пунктта:

«т» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «орган» сүзенә алмаштырырга;

«у» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «орган» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәдә:

исемендә «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр Татарстан Республикасы законнары белән башкасы билгеләнмәсә, казна учреждениесенә карата гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасының тармак компетенциясендәге республика башкарма хакимият органы яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3 пунктта:

«н» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «орган» сүзенә алмаштырырга;

«о» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «орган» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәдә:

исемендә «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

3 пунктта:

«р» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «орган» сүзенә алмаштырырга;

«с» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы» сүзләрен «орган» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин